# 2 НОМЕРЛЫ АЧЫК ТЫҢЛАУЛАР
# БЕРКЕТМӘСЕ

Иштуган тимер юл аерылышы бистәсе _2021 елның 6 августы

Катнашты: _21_ кеше

Рәис: Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгы урынбасары

Сәркатип: Иштуган авыл җирлеге Башкарма комитеты сәркатибе Г.Р. Хәбибуллина

Ачык тыңлаулар Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгының "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында" 2021 елның 28 июнендәге 105-п номерлы карары нигезендә үткәрелә.

КӨН ТӘРТИБЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча фикер алышу.

1.1. Тыңланды: Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы Э. Д. Рамазанов. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә гамәлдәге законнарны үтәү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 һәм 28 статьялары һәм "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 4 өлеше, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 5 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты турында фикер алышырга, аны килештерергә кирәк. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru. рәсми сайтында басылып чыкты.

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кермәде.

Карар: Гомуми фикер алышу нәтиҗәсендә, тәкъдимнәр булмауны исәпкә алып, бертавыштан түбәндәге карар кабул ителде:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты белән килешергә.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрергә.

Рәис: Р.Р. Закирҗанов

Сәркатип: Г.Р. Хәбибуллина

# АЧЫК ТЫҢЛАУЛАР

# КАРАР

Иштуган тимер юл аерылышы бистәсе                                   _2021 елның 6 августы

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Иштуган авыл җирлеге муниципаль
берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш
кагыйдәләре проекты белән килешү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы Э. Д. Рамазановның Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча чыгышын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң һәм Саба муниципаль районында ачык тыңлаулар турындагы Нигезләмә нигезендә гражданнар түбәндәге карарны кабул иттеләр:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты белән килешергә.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын раслау өчен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрергә.

Ачык тыңлаулар рәисе                                   Р. Р. Закирҗанов